РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОИКШУРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422066, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Старая Икшурма, ул.Ленина, д.17
тел.8 (84362) 41-6-47

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ ИКШЕРМӘ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

422066, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иске Икшермә авылы, Ленин урамы, 17 йорт
тел.8 (84362) 41-6-47

e-mail: sik.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
27.11.2024

КАРАР
№ 32

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мелкәткә капиталь ремонт ясауның кичектергесез ихтыяҗы барлыкка килгәндә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге башкарма комитетының 14.12.2018 ел №64 карары белән расланган Җирле бюджет акчалары исәбеннән кире кайтарыла торган һәм (яисә) кире кайтарылмый торган нигездә естәмә ярдәм күрсәтү очраклары исемлеге һәм тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

29.11.2021 елның №384-ФЗ Федераль законына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 14 нче декабрендә расланган «Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның кичектергесез ихтыяҗы барлыкка килгәндә җирле бюджет акчалары исәбеннән кире кайтарыла торган һәм (яисә) кире кайтарылмый торган нигездә өстәмә ярдәм күрсәтү очраклары тәртибен һәм исемлеген раслау турында» 64 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.6 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- субсидияләр алучыларның һәм товарлар җитештерүгә (реализацияләүгә), эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү турындагы шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) булып торучы затларның (дәүләт

(муниципаль) унитар предприятиеләрдән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм гавами-хокукый берәмлекләрнең устав (җыелма) капиталларында субсидияләр алучыларның һәм шулай ук мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашында аларның устав (җыелма) капиталларында коммерция оешмалары), субсидияләр бирүче бюджет акчаларын баш бүлүче (бүлүче) һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 3 пунктының 5 пунктчасында каралган тикшерүләрне гамәлгә ашыруга.»;

1.2. 4.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Субсидияләр бирүче бюджет акчаларын баш бүлүче (бүлүче) субсидияләр алучыларга һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 5 пунктында күрсәтелгән затларга карата бюджет акчаларын, аларның субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүләрне Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268_1 һәм 269_2 маддәләренә туры китереп».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы: А.И.Биккинин